# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Җәмгыяви иминлек фонды акчалары хисабыннан түләнгән дәвалану һәм ял итү юлламаларының хакыннан алынучы керем салымын түләүдән физик затларны азат итү турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында**

**1 статья.** «Җәмгыяви иминлек фонды акчалары хисабыннан түләнгән дәвалану һәм ял итү юлламаларының хакыннан алынучы керем салымын түләүдән физик затларны азат итү турында» 1994 елның 20 апрелендәге 2105-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, № 5-6) үз көчен югалтуын танырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыкканнан соң бер ай үткәч үз көченә керә, әмма физик затлар керемнәренә салым буенча чираттагы салым чоры башланган айның беренче көненнән дә иртәрәк түгел.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш. Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 21 ноябре
№ 1195